**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Бәркәтә авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге
составына керүче Бәркәтә авылы торак пунктында

**26 октябрь 2023 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлегенең Бәркәтә торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 600 сум күләмендә гражданнарның үзара салымын кертергә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк кешеләрдән, күп балалы аналардан, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операциясендә булган затлардан тыш.
2. Алынган акчаларны җибәрергә:

- «Шушма» елгасы аша җәяүлеләр кичү юлын төзү (култыксаларны (перила) ремонтлау, такталар урнаштыру);
- Бәркәтә торак пунктында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Бәркәтә торак пунктында стеланы төзекләндерү, реконструкцияләү, проект-смета документациясе өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, триммерлар, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга чыгымнар.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлегенең Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Бәркәтә авыл җирлеге башлыгы Р.М.Сибгатуллин